**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылында**
**халык җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 19 ноябре** **№ 4**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2025 елның 19 ноябрендә узган халык җыены беркетмәсе төзелде.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан тыш, 2026 елда гражданнарга үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 54 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында 32 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 32 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылында халык җыенын узган дип танырга, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. «Сез Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан тыш, 2026 елда гражданнарга үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан тыш, 2026 елда гражданнарга үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

кабул ителгән.

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27,

-ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы Р. С. Сәгдиев